| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КУАКБАШСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КУАКБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 октябрь 2020 ел Куакбаш № 3

Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымын (алга таба - салым) билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Җир салымы ставкаларын җир кишәрлекләренең кадастр бәясеннән чыгып түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

- 0,3% авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган торак пунктларда авыл хуҗалыгы файдалануындагы зоналар составындагы җирләргә карата;

- 0,3% торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен алынган (тәкъдим ителгән) җир кишәрлекләреннән тыш);

- 0,25% шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен алынган (бирелгән), бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата;

- 0,3% оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен тапшырылган Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата;

- 1,45% сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата;
- 1,10% административ һәм офис биналарын, мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү объектларын, физик культура һәм спорт, мәдәният, сәнгать, дин урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата;
- 0,05% сәнәгать җирләренә һәм башка махсус билгеләнештәге җирләргә кертелгән, гомуми файдаланудагы 1-3 категорияле автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата;
- 1,5 % башка җир кишәрлекләренә карата.

3. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләрен җир салымыннан азат итәргә:
- оешмалар - гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә (парклар, скверлар, шосселар, урамнар, тыкрыклар, машиналар, мәйданнар һәм гомуми файдаланудагы башка җир кишәрлекләренә карата); - оешмалар - гражданнар күмү өчен кулланыла торган җир кишәрлекләренә карата. - авыл җирендә яшәүче һәм пенсиягә чыккан ялгыз пенсионерлар

4. «Чернобыль АЭС һәлакәте аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы (1992 елның 18 июнендәге 3061-1 номерлы Россия Федерациясе Законы редакциясендә) «Маяк» җитештерү берләшмәсендә 1957 елда авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998г номерлы федераль законнар нигезендә 50% күләмендә ташламалар бирергә.

5. Әлеге карарның 4 пунктында каралган физик затларга ташламалар эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата гына бирелә дип билгеләргә.

6. Әлеге карар нигезендә җир салымын түләүдән азат ителгән юридик затлардан һәм гражданнардан кишәрлекләрне арендага (файдалануга) тапшырганда арендага (файдалануга) тапшырылган мәйданнан җир салымы алына.

7. Салым чоры дип календарь ел таныла. Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы таныла.

8. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 26 октябрендәге 9, 30.05.2017 елның 12 декабрендәге 12 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 32, 2019 елның 6 июнендәге 15, 9 августындагы 22, 2019 елның 15 октябрендәге 28 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

10. Әлеге карарны Куакбаш авылы-Карл Маркс урамы, 15 нче йорт,Сходнево-Чертанлы авылы,Ирек урамы,5А йорт адресы буенча авыл клубы бинасында,Чүти

авылында Тынычлык урамы,8А йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында («Авыл җирлекләре» бүлегендә) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo/tatarstan.ru) урнаштырырга.

11.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы
Совет рәисе Р.Р.Әхмәтҗанова